КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 сентябрь г.Казань № 1105

2024 – 2026 елларга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 – 2026 елларга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 995 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 995 нче карары белән расланган 2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 1 февраль, 82 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 995 нче карары белән расланган 2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 16 март, 259 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 995 нче карары белән расланган 2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 28 июнь, 760 нчы.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 8 сентябрь, 1105 нче
карары белән расланды

2024 – 2026 елларга дәүләт яшьләр сәясәте,
физик культура һәм спорт учреждениеләренең
норматив чыгымнары

| Т/с | Учреждение исеме | Хезмәт күрсәтү (эш) исеме | Норматив чыгымнар, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы учреждениеләре | | | |
| 1. | «Татарстан Республикасы Яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | яшьләр сәясәте өлкәсендә талантлы һәм инициативалы яшьләрне үстерү системасын формалаштыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең иҗади, һөнәри, интеллектуаль потенциалын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру | 76 957 200,0 |
| | | яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне инновацион, эшмәкәрлек, ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең гражданлык активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру | 51 304 800,0 |
| 2. | «Идел» яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | яшьләр сәясәте өлкәсендә талантлы һәм инициативалы яшьләрне үстерү системасын формалаштыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең иҗади, һөнәри, интеллектуаль потенциалын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру | 1 926 890,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне инновацион, эшмәкәрлек, ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең гражданлык активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру | 825 810,0 |
| 3. | «Иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү буенча «Созвездие – Йолдызлык» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | яшьләр сәясәте өлкәсендә талантлы һәм инициативалы яшьләрне үстерү системасын формалаштыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең иҗади, һөнәри, интеллектуаль потенциалын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру | 86 430 600,0 |
| 4. | «Сәләт» яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | мәгариф, фән һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә иҗтимагый әһәмиятле чаралар үткәрүне оештыру | 29 613 000,0 |
| | | яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрне инновацион, эшмәкәрлек, ихтыяри ярдәм эшчәнлегенә җәлеп итүгә, шулай ук яшьләрнең гражданлык активлыгын үстерүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру | 19 742 000,0 |
| 5. | «Студентларның хезмәт отрядлары республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | яшьләр сәясәте өлкәсендә талантлы һәм инициативалы яшьләрне үстерү системасын формалаштыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең иҗади, һөнәри, интеллектуаль потенциалын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру | 6 244 500,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 6. | «Патриот» спорт-патриотика һәм яшьләрне хәрби хезмәткә чакыру алдыннан әзерләү буенча республика үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләргә гражданлык һәм патриотик тәрбия бирүгә, яшьләр мохитендә толерантлык тәрбияләүгә, яшьләр арасында хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләрне формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру | 15 187 410,0 |
| | | мәгариф, фән һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә иҗтимагый әһәмиятле чаралар үткәрүне оештыру | 6 508 890,0 |
| 7. | «Яшьләр, инновация һәм профилактика программалары буенча «Навигатор» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | мәгариф, фән һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә иҗтимагый әһәмиятле чаралар үткәрүне оештыру | 12 319 560,0 |
| | | яшүсмерләр һәм яшьләрнең асоциаль һәм деструктив тәртибен профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар оештыру, социаль куркыныч хәлдә булган балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү | 9 239 670,0 |
| | | яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләргә гражданлык һәм патриотик тәрбия бирүгә, яшьләр мохитендә толерантлык тәрбияләүгә, яшьләр арасында хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләрне формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру | 9 239 670,0 |
| 8. | «Балалар һәм яшүсмерләр ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча «Җәй» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | махсуслаштырылган (юнәлешле) лагерьлар эшчәнлеген оештыру | 52 173 800,0 |
| 9. | «Черноморец» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | махсуслаштырылган (юнәлешле) лагерьлар эшчәнлеген оештыру | 8 972 200,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 10. | «Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең «Форпост» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләргә гражданлык һәм патриотик тәрбия бирүгә, яшьләр мохитендә толерантлык тәрбияләүгә, яшьләр арасында хокукый, мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләрне формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру | 7 045 200,0 |
| 11. | «Волга» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү) | 79 192 400,0 |
| 12. | «Костер» республика яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | белем алучыларның интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә сәләтләрен, фәнни (фәнни-тикшеренү) эшчәнлеккә, иҗади эшчәнлеккә, физкультура-спорт эшчәнлегенә кызыксынуын ачыклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чаралар, олимпиадалар, конкурслар оештыру һәм үткәрү | 19 398 100,0 |
| 13. | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт – Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү) | 110 886 400,0 |
| Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы учреждениеләре | | | |
| 14. | «Физик культура һәм яшүсмерләр спорты республика үзәге» дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе | белем алучыларның интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә сәләтләрен, фәнни (фәнни-тикшеренү) эшчәнлеккә, иҗади эшчәнлеккә, физкультура-спорт эшчәнлегенә кызыксынуын ачыклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чаралар, олимпиадалар, конкурслар оештыру һәм үткәрү | 5 985 612,0 |
| | | спорт әзерлеген үтүче затларның халыкара ярышларда катнашуын тәэмин итү | 460 431,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | спорт әзерлеген үтүче затларның спорт ярышларында катнашуын тәэмин итү | 460 431,0 |
| | | рәсми спорт чараларын оештыру һәм үткәрү | 2 302 160,0 |
| 15. | «Спорт сарае» дәүләт бюджет учреждениесе | спорт объектларына керү мөмкинлеген тәэмин итү | 146 158 129,0 |
| 16. | «Маяк» спорт комплексы» дәүләт автоном учреждениесе | спорт объектларына керү мөмкинлеген тәэмин итү | 33 059 628,0 |
| 17. | «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | спорт әзерлеген үтүче затларның халыкара ярышларда катнашуын тәэмин итү | 1 323 990,0 |
| | | рәсми спорт чараларын оештыру һәм үткәрү | 74 020 680,0 |
| | | спорт резервын әзерләүне оештыру һәм тәэмин итү | 2 635 330,51 |
| | | рәсми спорт чараларында спорт җыелма командаларының катнашуын тәэмин итү | 37 010 340,0 |
| | | спорт әзерлеген үтүче затларның спорт ярышларында катнашуын тәэмин итү | 7 600 670,0 |
| 18. | «Универсиада авылы» дәүләт автоном учреждениесе | дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү) | 1 175 316,0 |

___